ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-42-05, факс:2-80-13, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_09_» __07___2025ел №696

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 17 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 11.03.2021 елның «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан бинаны торак урын, гражданнар яшәү өчен яраклы (яраксыз) торак урын, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип тану максатларында бинаны бәяләү һәм тикшерү өчен ведомствоара комиссия төзү турында»гы № 162 карарына үзгәрешләр кертү турында»гы № 1832/1 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.01.2006 елгы "Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы нигезләмәне торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип раслау хакында»гы № 47 карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 17.11.2023 елгы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан бинаны торак урын, гражданнар яшәү өчен яраклы (яраксыз) торак урын, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип тану максатларында бинаны бәяләү һәм тикшерү өчен ведомствоара комиссия төзү турында"гы №162 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында"гы № 1832/1 санлы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карар кушымтасын әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Р.М. Якупов
2-42-05

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты
Карарына кушымта
«09» ___07___ 2025ел №696

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә бинаны торак урын, торак урынны гражданнар яшәү өчен яраклы (яраксыз), күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип тану максатларында аны бәяләү һәм тикшерү өчен ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| Самонина С.П. | Ведомствоара комиссия рәисе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе; |
| Захаров А.Н. | Ведомствоара комиссия рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы |
| Кәшафетдинов Р.Р. | Ведомствоара комиссия секретаре, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге белгече |

Ведомствоара комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Долгих В.В. | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең Бөгелмә, Азнакай, Баулы, Ютазы районнарында (Бөгелмә ТО) территориаль бүлеге җитәкчесе (килешү буенча); |
| Хаҗиева Р.М. | Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы вазыйфаларын башкаручы - Бөгелмә районара торак инспекциясе башлыгы (килешү буенча); |
| Лаптева С.В. | "Татарстан Республикасы Техник инвентаризация бюросы" АҖ Әлмәт филиалының Ютазы бүлекчәсе җитәкчесе (килешү буенча); |
| Латыйпова Г.А. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм |

| | |
|---|---|
| | шәһәр төзелеше бүлеге җитәкчесе; |
| Сәетгәрәева С.Р. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе урынбасары; |
| Миңневәлиев Р.Н. | «Ютазагражданпроект» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча). |